**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлегенең Яскүл авылында гражданнар җыены карары**

2 ноябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлегенең Яскүл авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елда Әлши авыл җирлегенең Яскүл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Яскүл авылында юлларны төзекләндерү юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Әлши авыл җирлегенең Яскүл авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлши авыл җирлеге башлыгы _________ В.П. Сюрмин

Гражданнар җыены секретаре _________ З.А. Гаврилова